Татарстан яшьләре

N 10

(8810)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

22 июль. 1993 ел

Бәясе килешү буенча.


* ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Премьер-министр ялгышамы?

Хөкүмәт җитәкчесе М.Сабировның күптән түгел үткән Югары Совет сессиясендә Татарстан белән Русия хөкүмәтләре арасындагы җиде үзара килешүне ни өчен парламент каравына чыгарырга теләмәвенә ачыклык керде.

Президент киңәшчесе Р.Хәкимовның телевидениедән депутат Ф.Сафиуллин белән корган әңгәмәсеннән аңлашылганча, премьер-министр Татарстан Конституциясенә каршы килә торган хөкүмәтара килешүләргә кул куйган. Үз сүзләрен дәлилләү өчен ул Русия белән ике арада таможня һәм милек мәсьәләләрен хәл итүче килешүләрне күрсәтте. Шул рәвешле, диде президент киңәшчесе, Татарстан делегациясенең күп тырышлык һәм көч куеп яклаган принципларына зыян китерелде. Әңгәмә барышында М.Сабировның үз вәкаләтләренә туры килмәгән бу гамәле парламент тарафыннан иртәмесоңмы тикшерелергә һәм җибәрелгән хата төзәтелергә тиешлегенә басым ясалды.

Киләсе сессиягә кадәр булган вакыт аралыгында (ә ул шактый озын) онытылырга өлгермәсә, әлеге аңлашылмаучылыкка ачыклык кертү парламентның күзге сессиясендә иң төп урынны алырга мөмкин. Ә эшнең мондый борылыш алуы исә хөкүмәтара 12 килешүнең калган бишесенә кул кую вакытын билгесез вакытка чигерер дип көтелә. Хәер, Русиядә арта барган билгесезлек һәм чуалышлар хәтта бер атнадан ни буласын да фараз итәргә мөмкинлек калдырмый.



Акча арта,

ләкин сез уйлаганча түгел

Дөнья имеш-мимешләр белән тулы. Мәсәлән, соңгы вакытта мондый хәбәр таралды. Янәсе, гражданнарның саклык кенәгәләрендәге акчалар арта. Төгәл саны да билгеле ди. Имеш, 1990 елның 1 гыйнварында саклык кенәгәләрендә күпме акча булган, шул 100 мәртәбә арта икән. Ышанычлы чыганаклардан алынган мәгълүматларга таянып, сезне тынычландырырга ашыгабыз: бүтән кайгыгыз булмаса, борчылмагыз! Акча артулар әлегә безгә лаемый. Бу имеш-мимешләрнең сәбәбе һаман да шул Русия ЮСына барып тоташадыр күрәсең. Халык депутаты Мукусёв бу мәсьәләне бер күтәреп караган иде, ләкин инфляциядән куркытыр инде, Русиядә бу адымны ясарга батырчылык итмәделәр. Ә Татарстан, Русия белән бер икътисадый галәмдә булганлыктан, берьяклы рәвештә генә бу адымны ясый алмый. Шулай булгач, җәмәгать, имеш-мимешләрнең дөреслектән ерак торуын әйтәсе генә кала.

Равил САБЫР.



Байлар йөрсен

Бәяләр арту чираты бу юлы нефть продуктларыннан башланды. Татарстан Министрлар Кабинетының 19 июльдәге күрсәтмәсе нигезендә аларның бәяләре түбәндәгечә билгеләнде: АИ-93 бензинының 1 литры - 105 сум, А-76 - 95 сум, ә дизель ягулыгы. - 90 сум. Шул рәвешле, нефтьнең бер тоннасы бүген 28 мең сумга җитте. Ә бу исә дөнья бәясе белән чагыштырганда бик кечкенә сан. Димәк, озакламый машинада утырып йөрү купшылык булып саналачак.

Башта су басты, аннары су бетте, аннары...

Башкалада бер-бер артлы көтелмәгән хәлләр килеп чыга. Көчле яңгырдан соң Воровский урамындагы асфальтта машиналар йөзеп йөргән булса, озакламый тулы бер Бахитов районы сусыз калды. Ә Ленин районы халкы ике көннән бирле телефоннан шалтырата алмый тилмерә. Боларның нилектән шулай икәнлеген әйтә алмыйбыз, чөнки ачыклар өчен телефон эшләми (редакция Ленин районында урнашкан).

Кибеттә юк, комбинатта буа буарлык

Шәһәр халкы җәй көннәрендә сөт ризыкларын ике мәртәбә азрак куллана башлаган. Моңа кыйммәтчелек тә, шәһәр халкының бакчаларда ятуы да сәбәпче түгел. Сөт комбинаты да продукцияне элеккедән күбрәк җитештерә. Хикмәт кибетләрнең тиз бозыла торган сөт ризыкларын кабул итмәүләрендә. Берничди суыткычлары булмаган сәүдә залларында кибетчеләр бүген атым юк урамда, кайгым юк буранда дип тик утырса, сөт комбинатында сөт ризыкларын кая куярга белми аптырыйлар. Атланмай гына да биредә көненә 12 тонна җитештерелә. Ә куллану нормасы - көнгә 4-5 тонна.

Законлы киосклар

Шәһәр башлыклары Казан урамнарындагы киоскларны тәртипкә китерү эшенә алындылар. Хәзер коммерция белән шөгыльләнүчеләр эт ояларына охшаган будкаларын теләсә кайда куя алмаячаклар. Киосклар тукталыштагы ышыклану урыны белән бербөтен итеп һәм архитектурага туры китереп эшләнә. Шунда ук газета ябыштырылган стенд, белдерүләр һәм реклама тумбасы, телефон-автомат та булачак. Әлбәттә инде, мондый законлы урын өчен законлы акча да түлисе була.

Акчам җитми - хат китмә

Почтадан канәгать булмаган казанлылар хәзер кыйммәтле почта хезмәтеннән файдалана алалар. Мәсәлән, хатыгыз Киров шәһәренә тиз барып җитсен өчен бары 5... доллар гына түлисе. Доллары булмаганнарны да кире бормыйлар - курс буенча "рубль" белән дә түләп була. Акчаң гына җитсен..

М.Мөлеков китте, низаг дәвам итә

• Татар милли хәрәкәтен гәүдәләндерүче БТИҮ җитәкчелегендәге тарткалаш дәвам итә. Бер-берсен республика мөстәкыйльлегенә һәм тулаем татар халкына каршы юнәлдерелгән эш алып баруда гаепләүче җитәкчеләр килешергә уйламыйлар да. БТИҮ эшләре белән идарә итүче Н.Нуриев кул куйган ике белдерүдә Н.Сафин җитәкчелегендә 10 июль көнне үткәрелгән ТИҮнең чираттан тыш пленумы милли хәрәкәттәге путч дип бәяләнә һәм аның бернинди дә вәкаләте булмавы күрсәтелә. "Татарстан һәм татар халкына ызгышлар түгел, ә конструктив һәм өзлексез эш кирәгрәк", - диелә анда. Дөрес сүзгә җавап юк дисәләр дә, каршы якның җавапсыз калмаслыгы шикле.

Әлеге белдерүдән соң БТИҮнең регионнардагы җитәкчеләре киңәшмә үткәрде. Анда рәис-координаторлар советы законлаштырылды. Оппозицияне җитәкчелек составына кертмәделәр, ә аның җитәкчесе Н.Сафинны залдан чыгып китәргә мәҗбүр иттеләр. М.Мөлековның БТИҮ рәисе-координаторлыгыннан азат итегез дигән теләге канәгатьләндерелде. Ул хәзер якларны яраштыру белән шөгыльләнәчәк..

Бер хәбәр уңаеннан

Әллә гадәт, әллә чир

Башкортостан хөкүмәтендәге тырыш түрәләр тагын элеккеге эшләренә - башкортлаштыру эшенә алындылар.

Бу юлы башкорт милләтен саклау һәм арттыру вазыйфасын үз өстенә "вак калибрлы артиллерия" - Башкортостан халык мәгарифе министры Р.Гордонов алды. Үзенең фәрманы белән ул барлык төр мәктәпләрдә башкорт телен һәм әдәбиятын өйрәтүне мәҗбүри итеп куя. Мөстәкыйль Татарстанда татар теле дәүләт теле булганда ни өчен әле мөстәкыйль Башкортостанда башкорт теле мәҗбүри булмаска тиеш, диярләр кайберәүләр. Ләкин монда хаталанырга кирәкми. Беренчедән, Башкортостанда башкортлар татарлар һәм урысларга караганда сан ягыннан азрак. Билгеле ки, бу ике ишле халыкның мәнфәгатьләрен - үз телләрен башкорт теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле итүне күрмәмешкә салышып булмый. Икенчедән, фәрман законга нигезләнергә тиеш. Ә Татарстаннан аермалы буларак, республикада бүгенгә кадәр телләр турындагы законның кабул ителгәне юк әле. Министрның бу фәрманы республика туфрагында яшәүче "җирле булмаган" халыкларның милли мәсьәләгә мөнәсәбәтен билгеләү өчен чыгарылган, күрәсең. Татар иҗтимагый оешмаларының һәм рус җәмәгатьчелегенең башкортлаштыруга теш-тырнагы белән каршы булуын һәм алга таба да нык торачаклыгын белгән югарыдагы җитәкчелек министрны вакытында төзәтер дип ышанырга кирәк. Югыйсә, тыныч республикалардан саналган Башкортостанда да аңлашулар башланачаклыгын фараз итү өчен күрәзәче булу кирәкми. Республика прокуратурасы фәрманның Башкортостан законнарына туры килмәве турында протест белдерде.

Әй әчәбез, әчәбез...

Казанда сәвит аракысы беткәнгә атна була инде. Шушы кызу көннәрдә күпләр телләрен асылындырып шәһәрнең бер башыннан икенчесенә аракы эзләп чапты. Тик юкка. Көндез чыра яндырып эзләсәң дә табарлык түгел аракыны! Моның сәбәбен ачыклау өчен без Сәүдә министрлыгы белән элемтәгә кердек. Алардан алынган мәгълүматларга ышансаң, башкаланы аракы белән тәэмин итү гадәти күләмдә алып барыла. Ягъни, көн саен сатуга якынча 5 мең декалитрга кадәр аракы сатуга чыгарыла. Ләкин соңгы көннәрдә аракы куллану бик нык арткан. Хикмәт шунда ки, Татарстан белән чиктәш өлкәләрдә һәм республикаларда спиртлы эчемлекләрнең бәясе шактый арткан, ә бездә әлегә элеккечә кала. Димәк, тиздән Татарстанда да бәя арта дигән сүз. Уйлавыбызча, сатуда аракы булмауның хикмәте кулланучыларның бу товарны күпләп алуында гына түгел. Күрәсең, читтән килгән эшмәкәрләр Татарстан аракысын оешкан төстә үзләренә ташыйдыр, шуңа күрә ул сатуга да аз чыгадыр.

Ә Казанда сатыла торган кайбер спиртлы эчемлекләрнең бәяләре белән сез дүртенче биттән таныша аласыз.

АЖДАҺАНЫҢ КАРАСЫ КАЛКА

- ...Шуннан соң Алып батыр, чуен чылбыр белән йөгәнләп, Аждаһаны халык янына алып чыга. Аны ындыр табагы хәтле казанга сала. Шуннан соң казан астына тау хәтле иттереп учак ягалар. Ул янганда бөтен тирә-юнь чүл кебек кыза. Аждаһа үкерә, дөньяны җимерердәй булып тартыша, авызыннан кап-кара төтен ургыла. Шуннан соң ул гомер буе эчкән каннарын коса башлый. Коскан каны да чеп-чем кара икән. Шуннан соң Аждаһаның кап-кара итләре таркалып китә. Шул итләрне тотып торучы кабыргалары да кап-кара икән моның... Инде, шуннан килеп, казанны ачып карасалар, кап-кара буяу белән кап-кара мае гына калган. Кап-кара буявын, юлга җәеп, асфальт иткәннәр, кап-кара маеннан беренче сортлы сабын ясаганнар. Илла да мәгәр сабыны файдага ярамаган...

.Мәрхүмә әнкәй!.. Белде микән "шуннан соң... шуннан соң..." диди сөйләгән әкиятенең бөтен дөнья халәтенә, бигрәк тә СССР дип йөртелүче Урыс Империясенә хас булачак, рас киләчәк бер вакыйга булырын? Миллионнарча кешеләрнең канын эчкәндә үз канын да эчкән Империянең аң-таң булып косачагын әзрәк шәйләде микән? Беренчедән - юктыр, икенчедән, аның өчен мин җавап бирә алмыйм. Әмма ул хәрам ризыкның эчне төртеп тишүен, таланган малның бәхет китермәвен, каргышның нәсел корытуын, күз яше койдырган гөнаһ ияләренең бер көн килеп тартышачакларын бик яхшы белә иде.

Ниһаять, безнең алда чын әкият: Аждаһа-Русия каргыш утында яна, шушы утка чыдый алмыйча сикергәндә гасырлар буе җыйган караларын, урысча сүз дә кыстырып җиффәрсәк, "чернота"лары калка. Чернобыль янындагы АЭС шартлавы Империянең котын алды. Хәбәрдарлык ирегә турында сөйли генә башлаган Кремль хуҗаларының, гүя, авызына чаптылар: Чернобыльдән кузгалган "чернота"ның Европа халкына чын афәт булып күтәрелүен, илдән-илгә аждаһадай шуышуын төрле ысуллар белән яшерергә тырыштылар. Искитәрлек бернәрсә дә юк, янәсе, кайгырмыйча яши бирегез... Миллионнарча гомерләргә зыян китерәчәк шушы вакыйганың асылы ачыкланып килгән көннәрдә тагын бер кара вәзгыять мәгълүм булды - Карабахта сугышлар башланды. Империя идеологлары анысына да халыкның күзен йомдырмакчы, бу хәлне "небольшой конфликт" итеп күрсәтмәкче иделәр дә - барып чыкмады; баксаң-күрсәң чын сугыш икән!.. Урыс империячеләренең милләтләрне бутап-болгатып бетерүләренең нәтиҗәсе икән! Кара әрмәннәр белән карапапахалар (әзәриләрнең этник төркеме) кара кан коешып ятканда СССР басуларында чернотелка дигән коңгызлар үрчи башлады. Буйлары 2 миллиметрдан 50 миллиметргача җитүче бу корткычлар барысын да рәттән ашый: үлән дә калмый, ашлык та. Алай-болай кырда ашар әйбер бетсә дә аптыраш юк - капчыктагы, лардагы, амбардагы онга кереп оялыйлар.

Ләкин Империянең ул хакта уйларга да вакыты юк. Карадәрья елгасы буенда үзбәкләр белән кыргызлар чәкәләшә. Кара диңгез буендагы караимнәр азатлык даулый. Чәчән-Ингуш республикасының Караболак поселогында кара асфальт җитештерүче эшчеләр баш күтәрә, унтугызынчы гасырда Русия тозагына төшкән карачәйләр тыпырчына...

Шул көннәрдә дөнья җәмәгатьчелеге Мәскәү Кремлендәге хакимият башлыкларыннан кара тартма таләп итә. Ягъни: "1983 елның сентябрендә йөзләрчә пассажирлы Корея самолетын бәреп төшергән идегез бит. Шуның кара тартмасын ачып, хакыйкатьне беләсебез килә". Горбачев алдый тегеләрне: имеш, алар сораган кара тартма самолет хәрабәләре белән бергә диңгезгә чумган. Нәкъ шул вакытта, ГКЧП вакыйгалары атнасында, Горбачев үзе дә югалтуга дучар була - кара чемоданы югала. Хәтәр чемодан! Шуны берәр малай-шалай тапса вә һәм дә аны ачып, эчендәге төймәләргә басып шаяра башласа, меңнәрчә атом-төш ракеталарының зәңгәр күккә ыргылуы ихтимал. Кара кайгыга калып, әнә шул кара чемоданны. Кара диңгез буендагы кара урманнарны актарып эзлиләр, адәм мәсхәрәләре! Әйтерсең лә нәртсыз-җирсез алкаш ике йомырка белән бер кукәй салынган чемоданын вокзалда югалткан...

Кара диңгез дигәннән, СССР җимерелгән көннәрдә, бәләкәй империя, ягъни Русия тагын кара хәсрәткә кала: бәксаң, Украина Кара диңгезне Русиягә бирмәскә маташа! Диңгез генә китсә әле бер хәл, йөзләрчә хәрби кораблар кулдан ычкынырга маташа. Ә инде Русия корал потенциалыннан башка яши алмый, чөнки ул талаулар, басып алулар белән генә тамак туйдырырга күнеккән Империя. Адмираллар, каракүл папахалар киеп кинәнгән генераллар, полковниклар Ельцинның бугазына басалар:

- Безнең ата-бабалар сугышып алган утрауны да, диңгезне дә бирмә!

Һәрьяктан аптырашта калган Ельцин, әзрәк ярдәме тимәсме, үзем йөгерәсе урынга ул йөгермәсме, дип, тагын бер карага - Черномырдинга өмет баглый, аны хөкүмәт башына куйдырта. Йөгерүен, чынлап та, әйбәт йөгерә Карамырза, ләкин ул да таралуга дучар булган империянең кыршауларын тотып тора алмый.

Россия үзенең бихисап колонияләрен саклау өчен съездларда, конституция киңәшмәләрендә кайнап яткан бер мәлдә, кара җирләре күзгә күренеп кими бара: ашкәртергә, тәрбияләргә, иген үстерергә кешеләре җитми. Сугышырга, провокацияләр, диверсияләр, интервенцияләр оештырырга, сафсата базары ясарга җитә, азык-төлек үстерүгә җитми!.. Хәер, Русиянең бөтен биләмәсе кара базарга әверелде. Чит илләр биргән долларлар да әнә шул кара базарның кара тишегенә ("черная дыра"сына) чумып бара. Кая монда кара халык - эшче халык турында уйларга вакыт?!

Өтелеп беткән империя өметен җуймаска маташа, кара эшкә атлыгып торучы кара эчле, кара йөрәкле затларны һәр төбәктән эзли, шуларга таянып, кара ниятен тормышка ашырмак була. Табуын да таба: әллә нинди Черновлар, Чернобровкиналар Татарстанны да болгатмакчы. Кара ниятле чыгышлар, кара фикерле мәкаләләр (клеветоннар) белән дөнья сасытып, Карабашта, Карадуганда, Карагундa, Карачишмәдә һәм тагын әллә нинди "кара"лы авылларда, поселокларда кара җәнҗал кузгатмакчылар.

Гомер-бакый кара каргыш җыйган Империя таркалуның соңгы стадиясенә керде. Ә үзе кара язмышка дучар булуын ишетмәскә тырыша. Ләкин соң инде: учак яна, казан кайный, аждаһа үрлекырлы сикерә. Карасы чыкканын, әҗәле җиткәнен бөтен дөнья күреп тора, һәр халык сөенә. Чөнки күршеңдә бандит яшәгәндә тыныч кына яшәп тә, баеп та булмый. Талаячак, үтерәчәк, яндырачак...

Фәнзаман Баттал

Эчке эшләр министры Искәндәр Галимов:

Тәртип булачак!

Татарстан эчке эшләр министры Искәндәр Галимҗанович Галимов 1950 елда туган. Югары юридик белемле, 1980 елда СССР Эчке эшләр министрлыгы Академиясен тәмамлаган. Республиканың эчке эшләр органнарына 1973 елда Алабугадагы махсус урта милиция мәктәбен тәмамлагач килә. Озак вакыт җинаятьләрне ачу системасында хезмәт итә. 1982 елда Чаллы шәһәр Советы башкарма комитетында Эчке эшләр идарәсе башлыгы урынбасары, 1984 елдан идарә башлыгы. 1988 елдан Казан шәһәре администрация башлыгының Эчке эшләр идарәсе башлыгы.

"Яңа себерке яңача себерә" дип халык тикмәгә генә әйтми. Яңа җитәкче үзе җитәкләячәк эш урынына яңа таләпләр, үзгәрешләр алып килә. Җинаятьчелек кызу темплар белән үсә, кеше гомере чебен гомеренә дә тиң булмаган хәзерге көннәрдә Президент Указы белән Татарстан эчке эшләр министры итеп Искәндәр Галимҗанович Галимовның билгеләнүе дә халыкта өмет чаткылары уятты. Бәлки... Хәер, фараз кылып утырганчы, әйдәгез, яңа министрның хәбәрчебез сорауларына биргән җавапларын укып карыйк.

- Искәндәр Галимҗанович, министр итеп сайлануыгызга әле санаулы гына көннәр үтсә дә, сез инде республикабызның берничә район һәм шәһәрләрендә булып урындагы хәлләр белән танышып кайтырга да өлгердегез. Сез булган урыннардагы һәм, гомумән, республикабыздагы тәртип саклау органнарының эшчәнлеге халыкны канәгатьләндерерлекме? Эшне нәрсәдән башладыгыз?

- Беренче хезмәт атнасын республикадагы җинаятьчелекнең күләме белән танышудан башладым. Анализ ясау һәм киләчәккә планнар кору өчен бу бик мөһим. Тәртип саклау органнарында эшләүче җитәкчеләр белән үткәргән беренче киңәшмәдә дә урыннардагы хәл һәм эшне ничек оештыру турында сүз барды. Татарстан Республикасы Президентының "Җинаятьчелеккә каршы көрәшү буенча гадәттән тыш чаралар" турындагы Законы буенча без аеруча киеренке шартларда эшләргә тиешбез. Бигрәк тә җинаятьчел төркемнәрне һәм аларның җитәкчеләрен эзләү буенча зур эшләр башкарыла. Юлларда машиналарны патруль постлары тикшерә. Коммерция эше белән шөгыльләнүче биналарда корал һәм наркотик матдәләр бармы-юкмы икәнлеге тикшерелә. Министрлыкның үзендә дә, урыннардагы барлык бүлекләрдә дә эшне яңача оештырырга туры килә.

Чаллыда җинаятьләрнең ачылу дәрәҗәсе канәгатьләнерлек түгел. Шуңа мин яңа гына Чаллыда булдым һәм андагы хәлнең торышы белән җентекләп таныштым. Чаллы янәшәсендәге Тукай, Алабуга, Минзәлә районнарындагы хәлләр белән дә кызыксындым. Миңа бигрәк тә Минзәлә районының эчке эшләр бүлеге башкарган эшләр ошады. Җитәкчеләре әле күптән түгел генә бу эшкә эшли башласа да, үзен яхшы яктан күрсәтергә өлгергән. Урындагы хәлләрне үз күзләрең белән күргәч, алга таба эшне ничек оештырырга икәнлеген чамалыйсың.

Җәмәгать тәртибен саклау буенча да эшне көчәйтергә кирәк. Махсус милиция нарядлары оештырылачак. Алар аеруча куркыныч җинаятьчеләрне эзләү белән шөгыльләнәчәкләр. Эт белән тәртип саклауга да зур әһәмият бирәбез. Эт белән милиционер да үзен ышанычлырак хис итә. Хезмәттән баш тартучы, эчеп, исереп йөрүче җилкуарлардан шәһәрләрне арындырасы бар. Андыйлар хәзер бик күп. Хроник авыруга әйләнгән эчкечеләрне хезмәт-төзәтү колониясенә җибәрәбез. Быел гына да 800 гә якын кешене шунда озаттык.

Оештыру эшендә дә үзгәрешләр бар. Мәсәлән, Чаллыда өстәмә рәвештә өч яңа милиция бүлеге ачу турындагы приказга кул куеп кайттым. Шәһәрнең Автозавод районындагы эчке эшләр бүлеге 400 меңнән артык кешегә хезмәт күрсәтә иде. Бу бик зур сан. Хәзер исә 100-120 мең кеше белән генә эшли торган берничә бүлек оештырылды. Шәһәр мэры өстәмә рәвештә ике район бүлегенә бина төзеп бирергә вәгъдә итте.

- Тәртип саклаучы милиционер үзе дә тәртипле булырга тиештер. Кызганычка каршы, халык арасында милиционерлар тарафыннан нахакка рәнҗетелүчеләр бик күп.

- Милициягә гадел, хезмәт сөючән кешеләр генә килсен иде дә, бит... Юк шул, гел андыйлар гына килми. Халык арасында милициягә гадәттән тыш үзенчәлекләргә ия булган кешеләр килергә тиеш дигән фикер дә йөри. Кеше нинди җәмгыятьтә үссә, тәрбияләнсә, безгә дә шундый кешеләр эшкә килә. Кызганыч, бүген бездә юрист һөнәренә укыган кешеләр генә эшләми. Төрле һөнәр ияләрен эшкә алабыз. Белемнәре дә төрле. Алардан яхшы милиционерлар әзерләгәнче шактый вакыт сарыф итәргә кирәк.. Без хәзер милициягә хезмәт коллективлары тәкъдим иткән, ышанычлы кешеләрне алырга тырышачакбыз.

- Милиционерлар бүген нинди өстенлекләрдән файдалана? Хезмәт хаклары күпме?

- Читтән карaганда милиционерның эше бик җиңел күренә. Урам буйлап резина таягын болгап тик йөри кебек. Постта торучы милиционерның эшен генә алып карыйк. Яңгыр, кар түгел, таш яуса да, ул сигез сәгать буе урынында басып торырга тиеш. Тәртип бозучыларны туктату, алар белән кешечә сөйләшү өчен генә дә күпме сәламәтлек кирәк. Хезмәтнең авырлыгын истә тотып, кызыксындыру чаралары да күп кулланыла. Махсус белеме булмаган, яңа гына армиядән кайтып эшли башлаучы гади милиционер да ким дигәндә 50 мең акча ала. Офицерлар 70-80 меңгә кадәр акча алалар. Стаж һәм хәрби дәрәҗә арткан саен акча да арта. Ял итәргә барганда юл хаклары да тулысынча эш урыныннан түләнә. Паеклар бирелә.

- Соңгы елларда телдә иң еш кулланылган сүз - мафия. Хәзер олысы да, кечесе дә шушы сүзне кабатлый. "Мафиягә каршы барырга ярамый - үтерәләр" дип, тыныч кына мафиянең корбаны булырга чакыручылар аеруча күп. Эчке эшләр министры буларак, сез бу турыда нәрсә уйлыйсыз? Мафия көннән-көн чәчәк атармы, әллә ул авызлыкланырмы?

- Мафия ул бик киң төшенчә. Гомумән, нәрсә соң ул мафия? Кемдер килеп нәрсәләр таләп итә икән - бу әле мафия дигән сүз түгел. Мафия ул - җинаятьчелек белән шөгыльләнүче кешеләр төркеме. Ул берничә кешедән алып берничә дистәгә кадәр кешене берләштерергә мөмкин. Җинаятьчелекне бетерү турындагы Указ булганда мафиягә каршы нәтиҗәле көрәш башлау өчен бөтен мөмкинчелекләр дә бар. Ә ничек көрәшергә соң? Аларны тәрбияләүнең нәтиҗәсе юк. Җинаятьчеләрне ничек тә тотарга һәм җаваплылыкка тартырга гына кирәк. Татарстан Республикасы Президенты Указы игълан ителгәннән соң бер ай үтүгә 1215 кеше кулга алынды. Шуларның 413е теге яки бу группа әгъзасы. Кулга алынучылар 30 тәүлеккә сак астына ябыла һәм бер үк вакытта тикшерү эшләре дә бара. Кулга алынган кешеләрнең 279ы җавапка тартылды. Шуңа, һич тә мафиядән куркырга ярамый. Җинаятьче группаларны эзләгәндә халык та "милиция кая карый?" дип кул кушырып кына утырмасын иде. Бездә "ышаныч" телефоны бар. Исем-фамилияңне әйтмичә, менә шунда җинаятьчеләр яши дип күрсәтү дә җитә. Милиция ул урынга бара, тикшерә. Фатир басу очраклары булганда да, бүлмәне җыештырыр алдыннан, иң элек милиция чакырырга, каракларның бармак эзләрен алырга кирәк.

- Дәүләт күләмендә җинаятьчелеккә каршы көрәш башлану нинди нәтиҗә бирер дип уйлыйсыз?

- Тәртип булачак дип уйлыйм. Соңгы айдагы уңай үзгәрешләр дә миңа шулай уйларга мөмкинчелек бирә. Машиналарны һәм шикле дип табылган фатирларны тикшерү нәтиҗәсендә бик күп корал җыелды. Бер пулемет, 20 автомат, 6 винтовка, 16 Макаров пистолеты, 38 граната, 6 меңнән артык патрон, 19 шартлаткыч җайланма, 56 сигнал бирүче ракета җинаятьчеләр кулыннан тартып алынды. Зурдан кубып эш башлаганбыз икән, һәрхәлдә, ул яхшы нәтиҗәле булачак.

Әңгәмәдәш Мансур МОРТАЗИН.



Иминлекне КГБ гына сакламый

Дөньяны шау-гөр китереп планетаның иң нык алга киткән җиде иленең очрашуы булып узды. Аңлашылганча, Токиога дөньяның иң югары даирәләрендәге җитәкчеләр килгән иде. Аларга куплар теш кайрап йөри, шуңа күрә президентларның иминлеге мәсьәләсе кабыргасы белән баса. ИТАР-ТАСС фотосында сез куркынычсызлыкны сакларга тиешле кешеләрне (ә алар 800гә якын) тренировка вакытында күрәсез.



Инде пенсияләрнең - 130, ә бәяләрнең 4000 мәртәбә һәм аннан да күбрәккә артуын исәпкә алсак, яшәү белән, үлем арасында нинди көрәш барганын чамаларга була. Бер көндезге аш бәясе (ашханәдә) 250-300 сум булгач, Татарстан Президентының халыкны адреслы социаль яклау программасы да кызганыч булып күренә (хәзер эшләүчегә караганда, урам чатындагылар күбрәк акча җыя - ходай күрсәтмәсен!)

Шулай да төп фикерем бүтән. Чәчән республикасы елына 6 миллион тонна нефть чыгарса да, анда ипи бәясе 1 сум, 750000 халыклы калмыклар да бездән өстен яшиләр, 25 кешелек парламент төзеп куйдылар. Безгә дә шундый парламент кирәк.

Даниял ХУҖИН.
Казан.

* * *

Хөрмәтле "Татарстан яшьләре"! Минем тыйнак кына ярдәмемне зур итеп кабул итүегез өчен бик зур рәхмәт. Киләчәктә дә сезнең белән үзара ярдәмләшеп яшәргә ходай насыйп итсен!

Сәлам белән,
МӨЗӘЯНӘ.
Чувашия,
Яльчик.

* * *

Безнең хәзер рухи азык та заманга яраклаштырылган. Балалар өчен чыгарылган бер китап күрдем. Мультфильм геройлары төшерелгән. Бик көлкеле карикатуралардан тора. Әйтик: һәркайсыбызга таныш Чебурашка - сумка сата. Чын крокодил тиресеннән тегелгәнне. Моның ишарәсе ни дисезме? Базар икътисады чорында бөтен нәрсә сатыла-алына, шул исәптән, дуслар да...

НАҖИЯ.
Чаллы.

* * *

Без күршебез белән икебез капма-каршы кешеләр. Мин әле дә булса заводта эшлим. Өчәр сменада. Тик гел мантый алмыйм. Хәтта бер яхшы келәм алу да минем өчен ерактагы хыял. Күршем исә рәсми рәвештә беркайда эшләмәүче бомж (үзе әйтүе буенча). Әмма ул череп баеган миллионер. Аның ике фатиры, өч бакчасы, өч машинасы бар. Дөрес, аның шөгыле бар. Ул әлек бер шәһәрдән товар алып икенче шәһәрдә сата иде, хәзер исә бүтән шәһәргә барып мәшәкатьләнми. Казан эчендә генә сәүдә итә. Бер кибеттән ала, икенчесендә сата. Менә нинди "тигез" дөньяда яшибез!

ШӘЙХНУР.
Казан.

* * *

Бу болганчык заман кайберәүләр өчен әй-һәй файдалы, җәмәгать. Бигрәк тә дезертирлар өчен. Безнең Татарстан армия хезмәтеннән качкан кешеләр өчен шәп сыену урыны булды. Безнең күрше малае әнә солдаттан качып кайтканына бер ел инде. Берәү дә эзләп килми үзен. Хәер, ул качу сәбәбен әйбәт аңлата. Имеш, Русия хөкүмәтенә түгел, ә туган Татарстанына хезмәт итәргә тели. Ел буе өйдә ятуына һәм кооператорлар белән алыш-бирешенә караганда, туган халкына ничек хезмәт итүе аңлашыла инде.

Тик бернәрсә башыма җитми, алай акча түгеп армия тотканчы нигә аны бөтенләй бетермиләр икән? Барыбер бит бер закон да, контроль да калмады.

И.А.
Казан.

Солтангалиевны да, Исхакыйларны да бер рәткә куеп, "халык каһарманнары" дип аңлату - югары дәрәҗәдәге икейөзлелек һәм халыкны алдауның яңа ысулы булып тора түгелме?

Фикер

ХАЛЫК УЛЫ ИСЕМЕ КЕМГӘ ТӨС



Бер яктан - Гаяз Исхакый, Садри Максуди кебек дистәләгән "ак эмигрантларны" һәм Совет хөкүмәте, коммунистик идеология белән килешмәгән һәм мәңгегә килешә алмаучы, большевиклар төзегән дәүләтнең төрмәләрендә әч-ялангач килеш газап чиккән һәм вакытсыз һәлак булган йөзләрчә, меңнәрчә милли каһарманнарыбызны, икенче яктан - 1917 елгы октябрь фетнәсенә кадәр үк коммунистлар партиясе әгъзасы булып, Ленинга Татарстанда чикләнмәгән диктатура урнаштырырга ярдәм иткән Солтангалиевны бер үк яссылыкта - татар халкының каһарманнары итеп карау - бүгенге көндә коммунистик системаның үзе үләр алдыннан "чиксез рәхәтлек чишмәсе", "гүзәл җәннәт фәрештәсе" дип безгә бүләк иткән, бары тик үзгәртеп кору чорында гына СПИД эләктергән Кечкенә Верасы ул.

Солтангалиевны нинди максат белән һәм ни өчен хәзер - алмашыну көннәрендә, күтәреп алдылар һәм милли каһарман ролендә күрсәтеп, аның эшчәнлеген генә түгел, хәтта шәхесен дә безнең татар халкы өчен мәртәбә дип аңлатырга тырышалар? Ниһаять, соңгы берничә ел дәвамында Татарстан газитләре, радио, телевидение генә түгел, бәлки башка илләрнең галимнәре дә кызыксына торган, аның эшчәнлеге хакында фәнни хезмәтләр языла торган шәхес - Мирсәет Солтангалиев чынлыкта кем иде соң ул?

Уя - Совет дәүләте составындагы бөтен мөселман халыклары өстеннән куелган иң эре комиссарларның берсе. Бу кеше миллионнар язмышын хәл итүдә Ленин, Сталин һәм Коммунистлар партиясенең төп җитәкчеләре белән бергә эш иткән, алар белән бергә эшләгән.

Солтангалиев татарларның 1917 елгы октябрь фетнәсендә катнашкан һәм, бу фетнә җиңгәч, яңа урнашкан власть башында торучыларның иң зурысына әверелгән. Ленин һәм коммунистлар партиясе гаебе белән гражданнар сугышында Көнчыгыш фронтта гына да уннарча мең ир-егетнең җаннары кыелган икән, монда иң эре татар комиссары Мирсәет Солтангалиевның гаебе бармы? Ил эчендә халыкларның бер-берсен үтерү өчен оештырылган шушы зур "сугышның иң кызган чагында Көнчыгыш һәм Төркестан фронтларында татар кызылармеецлары барлык составның яртысыннан күбрәген тәшкил итә иде", - дип язды Солтангалиев 1921 елның октябрендә. Шик тә юк, бу кадәр татар егетләрен һәм ирләрен берберен үтерүгә тартуда, аларны оештыруда һәм өйрәтүдә, сугышка хәзерләүдә Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясенең рәисе һәм Кызыл Армия политидарәсенең көнчыгыш бүлеге җитәкчесе Мирсәет Солтангалиев иң соңгы рольне уйнамагандыр.

Мирсәет Солтангалиевны татар халкының милли каһарманы итеп исбатларга омтылучыларның иң күренеклесе, һичшиксез, Казан дәүләт университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Индус Таһиров. Ул үзенең мәкаләләрендә Солтангалиевны хәтта өченче дөнья идеологы, колониаль халыкларның милли-азатлык көрәшләрендә төп теоретик итеп күрсәтергә омтыла. Ләкин бу мәкаләләрдә Мирсәет Солтангалиев хезмәтләренең конкрет эчтәлекләре дә, ул хезмәтләрнең исемнәре дә телгә алынмый. Аларны анализлап Солтангалиевның өченче дөнья идеологы икәнлеген исбатлау хакында сүз дә булырга мөмкин түгел. Кыскасы, Индус Таһиров язмаларында Солтангалиев хакында без гомуми фикерләр белән генә танышабыз. Мирсәетнең чын әсәрләрен күрмибез һәм белмибез.

Шуңа күрә Казан дәүләт университеты проректоры профессор Миркасыйм Госманов (бүгенге көндә тарих фәннәре буенча академик) "Татарстан яшьләре" гәзитенең 1989 ел 12 гыйнварында чыккан санында: "Сталин пропагандасы ярдәмендә контрреволюцион карачкыларның "дәвенә" әверелгән Солтангалиевның мөстәкыйль карашлы идеологик җитәкче дә, үз тәгълиматына ия политик теоретик та булмавы күптәннән мәгълүм, бүген аерата ачык. Гадәти генә урта кул партия функционеры булган ул. Ләкин андый карачкы (ясалма фигура) әле Ленин тере чакта ук власть өчен көрәш башлап җибәргән Сталинга эксперимент, тәҗрибә объекты сыйфатында кирәк һәм зарур иде", - дип язды.

Моннан 70 еллар чамасы элек Солтангалиев "җир йөзендә иң изелгән халык - мөселманнар, алар арасында да иң изелгәннәре - татарлар", - дип, профессор Таһиров аны "дөньякүләм тарихи әһәмиятле нәтиҗә" дип күрсәтә. Чынлап та, дөньяда иң изелгән халык ул вакытта татарлармы соң? Африка, Азия, Латин Америкасында яшәүче күп халыклар ул вакытта татарларга караганда да авыррак хәлдә яшәделәр, аларның изелүе татарларга караганда да көчлерәк иде. Таһиров мәкаләсендә татарларның ни рәвешле изелүе күрсәтелми, бары тик изелүләре хакында гына әйтелә, иң изелгән халык дигән фикер дәлилләр белән расланмый, ул гомуми сүз булып кына кала. Күрәсең, Солтангалиев та аларны күрсәтмәгән.

Дөньяда иң изелгән халыкны билгеләү өчен иң башта ул халыкның нинди социаль-иҗтимагый тормышта яшәвен, аның икътисадый аң һәм мәдәни үсеш дәрәҗәсен билгеләргә кирәк. Буйсынып яшәүче халыкның аң һәм мәдәни, икътисадый үсеш дәрәҗәсе югары булган саен, ул халыкны никадәр көчлерәк изәргә теләмәсеннәр, ул үзеннән шушы күрсәтелгән сыйфатлар белән түбәнрәк дәрәҗәдә, баскычта торган милләттән азрак изелә. Мәсәлән, рус миссионерлары, рус хөкүмәте татар халкын христиан диненә күчерергә никадәр генә теләмәсен, авылда да, шәһәрнең төп халкы арасында да ислам идеологиясе калды, ә мәдрәсә имамы - мулла әйткән сүзләр татар халкы өчен закон булды. Димәк, татарлар матди, сәяси яктан буйсынган булсалар да, рухи яктан буйсынмаганнар, ислам диненнән сатмаганнар, диненнән ваз кичмәгән безнең халык. Шул вакытка караган татар иҗтимагый тормышының бер-ике күренешен генә искә алыйк.

1917 елгы октябрь фетнәсенә кадәр татар зыялыларының шактый өлеше Казах далаларына, Урта Азиягә барып балалар укыткан, сәүдәгәрләре Троицк, Урта Азия, хәтта Ерак Көнчыгышка кадәр барып сәүдә иткәннәр. Татар авылы крестьянының хәле Һиндстан, Кытайда яшәгән төп массалар хәленнән өстенрәк булган. XIX йөздә татар халкы тормышында зур урын тоткан данлыклы мәдрәсәләр калкып чыга. Татарлар арасыннан Садри Максуди кебек күренекле дәүләт думасы депутатлары, Төрки дәүләте җитәкчесе данлыклы Ататөрекнең шәхси киңәшчеләре дәрәҗәсе югарылыгына кадәр күтәрелгән Йосыф Акчура кебек шәхесләр үсеп чыкты. Татар яшьләренең аз гына өлеше хәтта Петербург университетында укыды. 1917 елга кадәр укымышлылык ягыннан татар халкы хәтта руслардан да өстенрәк булды. Татарлар арасында тәнкыйди реализм ысулы белән иҗат итүче язучылар туды, татар театры барлыкка килде. Татар авылларында үткәрелә торган сабантуйлар, җыеннар татар халкы рухи үсешенең шактый югары дәрәҗәдә торганлыгын раслыйлар булыр. Шушы күрсәткечләргә ия булган халык дөньяда иң изелгән халык булырмы соң?

Сүз дә юк, Русияда башка халыклар белән бергә татар халкы да изелде, башка күп халыклардан артыграк та изелде, ләкин Солтангалиевның "татар халкы дөньяда иң изелгән халык" дигән фикерен ниндидер бер "дөньякүләм әһәмиятле нәтиҗә" дип күрсәтергә никадәр тырышсалар да, бу фикер фәнни яктан ялгыш.

Индус Таһиров Солтангалиевны дөньяга караштa "сыйнфыйлык принцибына беркайчан да ышанып бетми", - дип күрсәтә. Әгәр Татарстан җирендә уннарча мең татарны Көнчыгыш фронт өчен "сыйнфый дошманнарыгызны - эксплуататорларны сугышта үтерсәгез, җирле дә, иреклe дә булырсыз" дип, өстен сыйныфларга каршы көрәшкә күтәргән һәм Татарстан җирендә крестьянның иң соңгы умачка дигән онын Ленин туплаган бәндәләр өчен талап алуны оештырган кеше, Индус Таһиров әйткәнчә, "сыйнфыйлык принцибына беркайчан да ышанып бетмәгән" икән, ул вакытта кем соң ул татарның каһарманы булачак кеше?

Индус Таһиров фикеренчә, Солтангалиев "большевиклар белән аралашкан вакытында, саф һәм ихлас зат буларак, аларның сыйнфыйлык принцибы белән мавыгып ала, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукларын тормышка ашыру хакында большевиклар биргән вәгъдәләргә ышана".

Беренчедән, Солтангалиев большевиклар белән аралашып кына калмый, бәлки, халык теле белән әйтсәк, Татарстанда "ата большевик" була. Икенчедән, большевикларның "сыйнфыйлык принцибы белән мавыгып" кына калмый, шул принципларны Рәсәй эчендәге бөтен мөселман дөньясында төп тормышка ашыручыларның башында тора. Өченчедән, "милләтләрнең үзбилгеләнү хокукларын тормышка ашыру хакында большевиклар биргән вәгъдәләргә" ышанмый торган һәм бер вакытта да ышанмаячак булган чын милли каһарманнар урынына Индус Таһиров шул вәгъдәләргә алданган Мирсәет Солтангалиевны халык каһарманы итеп безнең алдыбызга китереп бастырмакчы була. Шул большевиклар биргән вәгъдәләргә алданмаулары аркасында китереп бастырмакчы була. Шул большевиклар биргән вәгъдәләргә алданмаулары аркасында гомерләренең иң соңгы көннәренә кадәр чит җирләрдә яшәгән Исхакыйлар, Максудилар, Акчуралар... истәлекләре алдында, аларның җаннары һәм рухлары алдында һәр саф күңелле татар бүгенге көндә үзен гаепле итеп сизмәсме соң?

Бәлки Солтангалиев, Индус Таһиров язганча, "саф һәм ихлас зат" та булгандыр, ләкин бу сафлык һәм ихласлылык Максудиларның Сорбонна университеты биргән аңнары белән чагыштырганда, аларның фикер һәм аң эшчәнлекләре белән чагыштырганда табигатькә чиксез якынрак. Чөнки аң инде бик күптәннән табигатьтән аерылган: аны табигать тудырган, ләкин аң үзен тудырган табигатьтән көчлерәк булырга тиеш.

Югары аңлы шәхесләр ялган идеяләргә дә, шул идеяне тормышка ашыручы икейөзле һәм ертkыч натуралы кешеләргә дә шул вакытта ук ышанмаганнар.

"Бүленмәс Русия" большевиклар властька килеп, үзләре "пролетариат диктатурасы" дип аңлата торган, чынлыкта коммунистлар партиясе җитәкчеләренең чикләнмәгән диктатурасы урнаштырылганнан соң Татарстанда милли каһарманнарыбызны эзәрлекләүчеләр ягындагы көчләрнең иң күренеклеләреннән берсе - Мирсәет Сотангалиев. Аны халыкка "ул безнең милли каһарманыбыз" дип аңлату, хәтта аңа һәйкәл кую, шушы аңлатуны төрле юллар белән тармакландыру, күпертү һәм халык аңламас хәлгә җиткерү иске партия номенклатурасына үзенең халык алдындагы җинаятен мәңгегә күмеп калдыруның ышанычлы ысулы.

Коммунистлар белән хезмәттәшлек иткән, яки үзләре үк "ата коммунист" булган ялган каһарманнарны халык күңеленнән кысрыклап чыгару юлларын эзләргә, шулай итеп халык күңелен, аны 70 елдан артык пычраткан чүп-чардан тазарта башларга кирәк. Бөтендөнья татарларының үзәге булган Казан татарлары арасында шундый хезмәтләр бастырылып, ул хезмәтләрнең эчтәлеге дөрес аңлатылса, чит илләрдәге галимнәр дә октябрь фетнәсеннән соң Ленинның пычагын халыкка каршы юнәлткән Солтангалиевлар хакында түгел, ә чын милләт хезмәтчеләре - Исхакыйлар, Максудилар хакында язачаклар.

Күңелендә милли хисләр тәрбияләгән, шуларны изге һәм кадерле итеп карап йөрткән һәр аңлы татар өчен Максудиларның, Акчураларның Төркия дәүләт җитәкчесе Ататөрекнең киңәшчесе буларак нәрсәләр эшләгәннәрен белү, ясалма юллар белән күпертелгән һәм дереслеге икеле булган Солтангалиев "өйрәтмәләренең" ниндидер Бен-Беллаларга тәэсирен белү һәм укуга караганда чиксез кызыклырак һәм җанына якынрак булачак.

Татар халкының күңелен Солтангалиев ягына вудару өчен Мирсәетнең 1917 елда уздырылган мөселман съездларында татар халкының милли мәсьәләсен хәл иткәндә Гаяз Исхакыйларга, Садрый Максудиларга каршы лагерьда һәм оппозициядә торуын да ышерәп калдыралар.

1917 елны большевиклар властьны үз кулларына алгач, татар халкының аерым бәйсез дәүләт булып төзелүенә каршы булган Ленин партиясе җитәкчеләре белән властька тагын да югарырак үрмәләүче Солтангалиев арасында көрәш башлангач, Мирсәетнең совет дәүләте составындагы төрки халыклары юлбашчылары белән яшерен хатлар алышканлыгы беленеп, ул кулга алынгач һәм тикшерү башлангач, тикшерүләр һәм сорау алулар, җәзалаулар һәм газаплы кәтүләр тәэсирендә, соңгы 17 ел эчендә Солтангалиевта милли тойгылар тирәнәйгәндер, үз халкы хакында уйланулар кискенләшкәндер?.. Бәлки бу уйлар, хәзер аңа исбатланмаган килеш зур хезмәт итеп тагыла торган пантюркизм, панисламизм идеяләре булып формалашкандыр? Ләкин бу уйлар, бу идеяләр Солтангалиев большевик буларак эшләгән эшләр белән чагыштырганда чиксез кечкенә һәм аңа кадалырга тиешле пычактан тайпылу өчен генә туган идеяләр түгелме?

Шунысы ачык, коммунистлар партияләре бер илдә дә, бер вакытта да халыкка бәхет тә, шатлык та, рәхәтлек тә алып килмәделәр, чөнки коммунизмның төп принцибы - тигезлек һәм азатлык өчен көрәш, хосуси милекне җәмәгать милкенә әверелдереп, дөньяда изүне мәңгегә юкка чыгару - халыкның бер өлешен талау, көчләү һәм үтерү юлы белән генә тормышка ашырылырга мөмкин. Ләкин кешелек дөньясы бу принципларны кабул итмәде.

Шик тә юк, шушы партиянең татар халкы арасында төп җитәкчеләреннән берсе буларак, Солтангалиев та бу юлдан берничек тә читләшә алмады һәм читләшә алмаячак иде. Сүз дә юк, М.Солтангалиев - зур шәхес. Трагик шәхес. Аның фаҗигасе Ленин тәгълиматы белән алдануында һәм шул юлда корбан булуында.

Тәлгать ФАТЫЙХОВ,
Саба районы

***Редакциядән.** Бу бәхәсле мәкалә газетабызда шактый кыскартып бастырылды. Аның тулы вариантын "Аргамак" журналының 7 нче санында укырга мөмкин.*



Тәмәке өйләндерә

Малайядагы темияр ыруында, әгәр егет белән кыз чиратлашып бер сигаретны тартып бетерсәләр, алар шунда ук ир белән хатын булып санала.

Иң бәхетле пар

Португалиянең Эвера шәһәрендә ирле-хатынлы Маттеуслар икесе дә бер көнне - 1801 елның 1 гыйнварында дөньяга киләләр. Нәкъ 20 яшьтә өйләнешәләр һәм 80 ел буе чукердәшеп гомер итәләр. Бәхетле парның дөньядан китүе дә бер көнне - 1900 елның 31 декабрендә була.

Чәчәк кәләшләре

Һиндстанда яшәүче бер катлау халыкның кызлары бәйрәм көнне генә кияүгә чыга алалар. Ләкин бу бәйрәмнең хикмәте бар - ул 12 елга бер генә килә. Шуңа күрә әлеге кырыс законны әйләнеп үтүнең әмәлен дә тапканнар: кызлар иң элек... чәчәк букетына кияүгә чыгалар. Чәчәкләр шиңгәннән соң "кәләш" тол хатын дип санала. Ә теге закон тол хатыннарга кагылмый..

Нәфселе кияү

33 яшьлек италияле Франческо Галеттины артыграк яратып ташлаганы өчен 2,5 елга ирегеннән мәхрүм итәләр. Ул газеталардагы белдерүләр буенча берьюлы җиде кыз белән никахлаша һәм . һәрбер кәләшеннән берәр миллион лир "задатка" ала.


"Зәңгәрләр" борчыла

Мәскәүдәге сексуаль азчылыкка керүче "зәңгәрләр" һәм "алсулар" Русия хөкүмәтендәге гомосексуалистларның исемлеген бастырып чыгарырга җыена дигән имеш-мимешләр күпләрне хафага салды. "Зәңгәрләр" җитәкчесе Р.Калинин үз "полкташлары"на карата мондый рәхимсез чараны кулланмаячакларын, ә бу эшне бары тик "Столица" журналы гына башкарырга мөмкин икәнлеген әйтте. Аның раславынча, журналда озакламый күренекле кешеләрдән саналган 200 "зәңгәрнең" исем-фамилиясе басыла дигән хәбәрдән соң кызык хәлләр башланган. Фаш ителүдән курыккан зур кешеләр әлеге исемлеккә керүкермәүләрен белешә башлаганнар. Шул рәвешле журнал хезмәткәрләре өстә утыручылар турында ярыйсы гына кызык мәгълүмат туплаганнар.

"Доверие" чек-инвестиция фонды

- Фонд акцияләрен 1993 елның 1 маена кадәр алган гражданнарга быелның 20 июленнән аванс рәвешендә 200% еллык дивидентлар түләнә башлавы турында хәбәр итә.
- Сезнең ваучерларыгызны зур керемле дистәләгән оешмалар акцияләренә алмаштыра.
- Гражданнарның чекларын Татарстан Республикасы һәм Россиянең зур шәһәрләре (Мәскәү, Санкт-Петербург һ.б.) күчемсез милкенә урнаштыра.
- Бер приватизация чегы фондның ун акциясенә алмаштырыла.
- Пенсионерлар, инвалидлар, сәламәтлек саклау өлкәсендә эшләүчеләр регистрация өчен түләү бәясеннән азат ителәләр.
- Гражданнарның приватизация чекларын сатып ала.
- Фонд акцияләренә Татарстанның барлык почта бүлекләрендә 20 июльдән соң язылырга мөмкин.
- Белешмәләр алу өчен адрес: Казан шәһәре, Восстание урамы, 82 йорт, 226 бүлмә. Телефон: 42-59-04.

Без сезнең ышанычыгыз өчен җаваплы.



Табигатьтә мөгезборыннар көннән-көн азаю сәбәпле, аларны саклау кампаниясе җәелдерелде. Ә менә цивилизацияле тоткынлык шартларында бу сирәк җанварлар үзләрен бер дә начар хис итми. Швейцариянең Базель шәһәре зоопаркында 1956 елдан бирле 25 мөгезборын дөньяга килгән инде.

ИТАР-ТАСС фотосы.

Татарстанда бердәнбер полиграфия лицее

9 сыйныфтан соң түбәндәге белгечлекләргә укучылар кабул итә:
- басма һәм текст формалары әзерләү буенча техник-технолог;
- басу процессы техник-технологы.

Уку срогы 3,5 ел.
- электр җиһазларын ремонтлаучы электромонтер;
- кибетче.

Уку срогы - 3 ел.

11 сыйныфтан соң:
- суд сәркатибе һәм суд башкаручысы;
- сәркатиб-машинада басучы;
- тышлаучы.

Уку срогы - 10 ай.

Укулар атнага биш көн булачак һәм 1 сентябрьдән башланачак.

Стипендия күләме 3150 сум, туклану өчен махсус түләнә.

Мөрәҗәгать итү өчен адрес: 420111, Казан шәһәре, Городецкий урамы, 11/6. "Ирек мәйданы" тукталышы.

Телефоннар: 32-35-28, 32-68-00, 32-01-65.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Газетада котлау турында белдерү бастыру өчен редакция счетына 3000 сум акча күчерергә һәм акча күчерү турындагы квитанция белән котлау текстын редакция адресына җибәрергә кирәк. Хатларыгызны бер ай алдан җибәрүегезне сорыйбыз.

* * *

Азнакай районы, Тымытык авылында яшәүче кадерле әти-әниебез Рәшит һәм Дәүҗия Шәйдуллиналарның 20 июльдә бергә яшәүләренә 20 ел тулды. Әтиебез белән әниебезгә озын гомер, нык сәламәтлек, тормышларында күп шатлык, бәхет, уңышлар, тигез тормыш телибез. Шушы ук көнне энебез Рөстәмгә дә 19 яшь тулды. Аңа да озын гомер, сәламәтлек, бәхет теләп калабыз.

Иң изге теләкләр белән: Раушания, Илгиз.

* * *

Лаеш районы, Габишево поселогында яшәүче әниебез Исламия Шәфигуллинага 20 июльдә 45 яшь тулды. Кадерле әниебез! Сине чын күңелдән туган көнең белән тәбрик итәбез, озын, тыныч гомер, матур көннәр, шатлык, бәхет телибез.

Иң изге теләкләр белән: кызларың Алсу, Гөлнар, туганнарың.

* * *

Актаныш районы, Тат.Суксу авылында яшәүче әниебез Зөлхая Исламгәрәеванага июль аенда 65 яшь тулды. Әнкәй! Сине чын күңелдән туган көнең белән котлыйбыз, кояштай озын гомер, корычтай нык сәламәтлек, киләчәк көннәреңнең шатлыкка күмелеп үтүен телибез. Һәрчак шат күңелле булып, балаларыңның игелекләрен күреп, кайгы-хәсрәтсез яшә.

Изге теләкләр белән: Төрекмәнстанда яшәүче кызың һәм киявең исемнәннән, Диләрә, Фәнил, Ирхәт, Ирмат; оныкларың, туганнарың.

* * *

Баулы районы, Крым-Сарай авылында яшәүче әниебез Васила Әхмәтҗановага июль аенда 50 яшь, ә Воркута шәһәрендә яшәүче абыебыз Фирдәүс Әхмәтҗановка 30 яшь тулды. Кадерле әниебез һәм абыебызны олы бәйрәмнәре белән чын күңелдән тәбрик итәбез, саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, озын гомер телибез.

Иң изге теләкләр белән: уллары, кызы, килене, оныклары.

* * *

Сарман районы, Рантамак авылында яшәүче әниебез Халисә Кәримовага июль аенда 60 яшь тулды. Һәрвакыт кайгыртучан, йомшак күңелле, ярдәмчел, мәрхәмәтле әниебезне чын күңелдән олы юбилее белән котлыйбыз. Сау-сәламәт, күңел тынычлыгы белән мул тормышта, балаларының игелеген күреп озак яшәвен телибез.

Изге теләкләр белән: килене, уллары һәм оныклары.

* * *

Саба районы, Урта Саба авылында яшәүче сеңлебез Язилә Сәләхиевага июль аенда 23 яшь тулды. Сине туган көнең белән чын күңелдән котлыйбыз. Туасы таңнарың өметле, көннәрең куанычлы, тәнең сәламәт, гомерең озын булсын.

Апаң Зөһрә, җизнәң Рәис.

Норильск шәһәре.

... кая безнең шешәбез?

Буш аракы шешәсен (чебурашканы) 20 сумнан кабул итәләр.

Аракы бәяләре (сумнарда):

Русская - 565
Московская - 565
Moscovska - (Германиядә эшләнгән 1 л) - 2500
Пшеничная - 620-650
Smirnoff - 3150-3800
Rasputin - 2000-2500
Konzumni - 2000
Kristal - 2400
Gorbachof (Горбачев) - 4500
Золото России - 2000
Terminator - 1200-1500
Slavyanska - 1300
Wollbrink - 2300
Азык спирты - 950.
Whisky (виски, Кытайда эшләнгән) - 1500
Tanduay (ром) - 2500

Ликерлар:

Киви - 1750
Бананныкы - 2500
Чикләвекнеке - 1620
Грушаныкы - 1620
Шоколадлы - 1620
Апельсинныкы - 1620
Абрикосныкы - 1620
Куракау - 1620
Blanche Laveur cherry (чия ликеры) - 2000-2200
Perpmintovy - 3000

Шәраблар:

Портвейн грузинский - 430
Портвейн розовый - 345
Портвейн 777 - 478
Полянка - 510
Агдам - 400-500
Алиготе - 360
Албена - 1600

Шампан шәраблары:

Советское - 1500-2200
Рождественское - 1700
Советское игристое - 1700
Anis - 2000
Baron - 2300

Амаретто:

Fir-Cola - 1300
Salute - 3500
Cazanova - 2000

Коньяклар:

Азербайджанский - 978
Brendi - 1200

Сыралар:

Колос - 200
Экспресс - 96-160
Рижское - 180
Чит илнекеләр 1700гә кадәр

Хушбуйлар:

Шипр - 164
Тройной - 170
Командор - 400
Геракл - 600
Татлы сулар - 900-1200
Алма согы 3 л - 420
Фанта - 160-250
Кефир - 34-49
Кымыз - 70

R.S. Әлеге бәяләр - хезмәт хаклары артканчы җыелган иде. Аларның гәзиттә басылуы объектив сәбәпләр аркасында тоткарланды. Шуңа күрә бәяләрнең бераз артуы да бик мөмкин.

Аракы эчүдән котылырга ярдәм итәбез

Күренекле психотерапевт Рамил Гарифуллин аракы эчүдән котылу буенча алга киткән алымнар кулланып даими рәвештә дәвалау үткәрә. Аның исәбендә - әлеге куркыныч авырудан котылган меңләгән кешеләр.

Түбәндәге адрес һәм телефон буенча көн саен мөрәҗәгать итәргә мөмкин: Казан, Г.Кутуй урамы, 88 йорт. 23 номерлы поликлиника. Телефон: 75-38-14.

Для Вас, МУЗЫКАНТЫ!

Электромузыкальные инструменты ведущих фирм мира; профессиональное оборудование для аудио-студий и концертных площадок; звуковые адаптеры и музыкальные программы для компьютеров в нашем магазине в центре Москвы.

тел. (095) 928-3852

Весь мир музыкального бизнеса - в телефонном справочнике "ИМПРЕСАРИО-93".

тел. (095) 248-9046

Услуги нашей профессиональной аудио-студии!

тел. (095) 248-9036

И все это - Турне

тел. (095) 248-2811
факс (095) 241-0847

МОСКВА

ТЯ

Баш мөхәррир урынбасары Минназыйм СӘФӘРОВ (53-07-52)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2. "Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-50 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - сәяси тормыш һәм тәрҗемә, фән һәм мәгариф
53-07-56 - мәдәният-сәнгать
53-07-52 - табигать, авыл тормышы

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ. РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 203620

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе. Газета басылуга кул кую график буенча 18 сәгатьтә. Бу санга 14 сәгатьтә кул куелды. Заказ 6120